**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БӨГЕЛМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
«ВЯЗОВКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
СОВЕТЫ III ЧАКЫРЫЛЫШ**

**КЫРЫК ИКЕНЧЕ СЕССИЯ**

**№ 1 КАРАР**

Вязовка бистәсе 2019 елның «11» ноябре

«Вязовка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджетыннан
Бөгелмә муниципаль районы бюджетына
җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча
җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда
барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен
финанслашу максатларында субсидияләр бирү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 142.3 статьясы нигезендә
Вязовка авыл җирлеге Советы
карар чыгарды:

1. «Вязовка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджетыннан Бөгелмә муниципаль районы бюджетына субсидияләр җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча Бөгелмә муниципаль районы җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында бирелә (алга таба – субсидияләр).

2. Субсидияләр чираттагы финанс елына һәм план чорына «Вязовка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджеты турында Вязовка авыл җирлеге Советы карарында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

3. Әлеге карар нигезендә бирелә торган бюджет ассигнованиеләрен баш бүлүче - «Вязовка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты.

4. Бөгелмә муниципаль районы бюджетына субсидияләрне бүлү Вязовка авыл җирлеге Советы тарафыннан чираттагы финанс елына һәм план

чорына «Вязовка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджеты турында карар белән раслана.

5. Субсидияләр бирү максатлары һәм тәртибе «Вязовка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты һәм Бөгелмә муниципаль районы башкарма комитеты арасында төзелгән килешү нигезендә билгеләнә.

6. Килешүдә түбәндәге төп нигезләмәләр булырга тиеш:

а) субсидиянең максатчан билгеләнеше;

б) субсидия бирү һәм тоту шартлары;

в) субсидия бирүгә каралган бюджет ассигнованиеләре күләме;

г) субсидия күчерү графигы.

7. Килешүгә Бөгелмә муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе һәм «Вязовка авыл җирлеге»муниципаль берәмлеге башкарма комитеты җитәкчесе кул куя.

8. Субсидияләр «Вязовка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты тарафыннан Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсенең территориаль органнары исәбенә бирелә.

9. Башка бюджетара трансфертларның максатчан кулланылышын законнар нигезендә Бөгелмә муниципаль районының финанс органы контрольдә тота.

**«Вязовка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы»** **В.Н.Соколов**